**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Важашур авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Важашур авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Сутер авылы, Яшьлэр урамы, 1д нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Важашур авылының Киров, Сахалин, Яшел, урамнарында вак таш түшәп, юллар төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Важашур авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Важашур авылында урам яктырткычларын төзекләндерү һәм сатып алу?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Важашур авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы: П.Л.Иванов